АГЕНТСТВО ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

«19» июня 2025 ел № 14

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында коррупция куркынычы белән бәйле булган вазыйфаны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеген раслау турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль законны, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында коррупция куркынычы белән бәйле булган вазыйфаны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге № УП-701 Указын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында» 2009 елның 30 декабрендәге УП-702 номерлы Указын үтәү өчен

БОЕРУ:

1. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында коррупция куркынычы белән бәйле булган вазыйфаны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган кушымта итеп бирелә торган Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеген расларга (алга таба — Исемлек).

2. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының хокукый һәм документлар белән тәэмин итү бүлегенә:

2.1. «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль законның 12 статьясында каралган чикләүләрне, бурычларны һәм җаваплылыкны Исемлеккә кертелгән вазыйфаларны биләгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә эштән азат ителгәндә аңлатырга.

2.2. Әлеге боерыкны Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә җиткерергә.

3. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының «Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында коррупция куркынычы белән бәйле булган вазыйфаны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеген раслау турында» 08.07.2024 № 23 боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче Т. И. Миңнуллина

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы боерыгы белән расланган

19 июнь 2025 № 14

**Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында коррупция куркынычы белән бәйле булган вазыйфаны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеге**

| № | Вазыйфа исеме | Вазыйфалар саны |
|---|---|---|
| | Җитәкчелек | |
| 1 | Җитәкченең беренче урынбасары | 1 |
| 2 | Җитәкче урынбасары | 2 |
| | Инвестицион проектларны экспертизалау бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы киңәшче | 2 |
| | Инвестиция проектларын алып бару һәм ярдәм итү бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы киңәшче | 1 |
| | Мәгълүмат-аналитика бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| | Дәүләт-хосусый партнерлыкны үстерү бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы киңәшче | 1 |
| 3 | Әйдәп баручы белгеч | 2 |
| | Хокукый һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы киңәшче | 1 |
| | Финанс хисабы һәм дәүләт сатып алулары бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы белгеч | 2 |
| | Беркетмә бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| | Инвестицияләрне җәлеп итү буенча эшчәнлекне координацияләү бүлеге | |

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| | Инвестицион җәлеп итүчәнлекне арттыру бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| | Инвестиция проектларын гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм структуралаштыру бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Бүлек башлыгы урынбасары | 1 |
| 3 | Әйдәп баручы киңәшче | 2 |
| 4 | Әйдәп баручы белгеч | 2 |
| | **Барлыгы:** | **27** |